РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ МИЧАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422055, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с. Старый Мичан, ул.Школьная, 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МИЧЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422055, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Иске Мичэн авылы, Мэктэп урамы,
12 нче йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

21.06.2024 — № 10

Муниципаль хезмәтне оештыру
вәкаләтләрен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә нигезләнеп, Саба муниципаль районы Советының 23.04.2024 елның 262 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичэн авыл җирлеге Советы Карар итте:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы тәкъдимен кабул итәргә һәм Саба муниципаль районына түбәндәге җирлек вәкаләтләрен тапшырырга:

– муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне, шулай ук муниципаль хезмәткә кагылышлы норматив-хокукый актларны раслау;

– муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс оештыру һәм үткәрү;

– муниципаль хезмәтнең вакантлы идарәче вазыйфаларын һәм вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс оештыру һәм үткәрү;

– муниципаль хезмәткәрләрнең аттестациясен һәм квалификация имтиханын оештыру һәм үткәрү;

– муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә, җирлек хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү эшен оештыру;

– муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм бу мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү;

– муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышларын үткәрү;

– муниципаль хезмәткәрләргә карата мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында хезмәт тәртибенә таләпләрнеһәм (яки) таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләрне карау;

– Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон һәм коррупциягә каршы тору өлкәсендәге башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итүдә һәм муниципаль хезмәткәрләрнең «җирлек» чикләүләрен һәм тыюларын,

мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәүләрен тәэмин итүдә;

– муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия утырышын оештыру һәм үткәрү;

– -"Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында билгеләнгән тәртиптә эш башкару;"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм кадрлар эшендә кулланыла торган башка мәгълүмат системаларында билгеләнгән тәртиптә эш башкару;

– "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәмкадрлар эшен дә кулланыла торган башка мәгълүматсистемаларында билгеләнгән тәртиптә эш башкару;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрын һәм муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару;

– муниципаль вазыйфаларны биләгән затларның пенсиясенә өстәмә түләүләр, муниципаль хезмәткәрләрнең күпьеллык хезмәте өчен пенсияләр рәсмиләштерү өчен документлар әзерләү;

- муниципальвазыйфаларга, контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны кабул итүне оештыру

2.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районнары Советы һәмБашкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/mishan

4.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мичән авыл җирлеге башлыгы А.А.Гараев